СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_28_»__апрель__ 2026 ел** **№ __48__**

**“Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” һәм “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Арча район Советының закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, “Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында” Арча район Советының 2026 елның 9 февралендәге 30 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкының Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керүче “Арча шәһәре” һәм “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ризалыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге территориясе составына кертү юлы белән Арча район Советы **карар кабул итте:**

1. “Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” һәм “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа Материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Арча район Советы вәкиле итеп Мөхәмәдияров Рамил Данил улын - Арча муниципаль район Башлыгы урынбасарын билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль район башлыгы урынбасары Р. Д. Мөхәмәдияровка йөкләргә..

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе А.Г.Хисаметдинов